КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 6 март г.Казань № 135

Чистай муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Чистай муниципаль районында урнашкан 0,3756 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:42:180402:510 кадастр саны белән ял итү (рекреация) объектларын урнаштыру максатларында махсус сакланыла торган территорияләр җирләре һәм объектлар категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин